**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__19_» _____03____ 2025 ел.** **№ __62____**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 01 октябрендәге 185 номерлы «2025 елга «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Рәисе 2025 елның 07 февралендәге 5600-МР номерлы Татарстан Республикасының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына 2025 елга өстәмә индексация турындагы карары һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе хатын үтәү нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 01 октябрендәге 185 номерлы «2025 елга «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар» 1 нче кушымтаның 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында азык-төлек продуктларына чыгымнар нормативы

| Мәктәпкәчә мәгариф оешмасының эш сәгатьләре саны | Азык-төлек продуктларына, кеңгә/тәрбияләнүчегә чыгымнар нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми үстерү төркемнәре (шул исәптән төрле яшьтәгеләр) | | шифаханә төркемнәре | |
| | 2 айдан 3 елга кадәр | 3 елдан алып мәгариф мөнәсәбәтләре | 2 айдан 3 елга кадәр | 3 елдан алып мәгариф мөнәсәбәтләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | туктатылганга кадәр | | туктатылганга кадәр |
| 3-4 | 33,88 | 42,65 | 0 | 0 |
| 5-6 | 81,28 | 102,39 | 0 | 0 |
| 7-12 | 135,49 | 170,64 | 175,78 | 234,39 |
| 24 | 169,34 | 210,66 | 219,73 | 289,36» |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов